ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 октябрь, 2017 ел № 20/11

Яр Челлы шәһәре муниципаль берәмлеге административ комиссиясенең эш Регламентын раслау турында

Татарстан Республикасының 2005 елның 30 декабрендәге «Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары җирле үзидарәләренә административ комиссияләр һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында» 144-ЗРТ санлы Законына, шәһәр Уставының 28 маддәсенә нигезләнеп,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге административ комиссиясенең эш Регламентын кушымтадагыча расларга.

2. Гамәлдән чыккан дип танырга:

1) Шәһәр Советының 2006 елның 06 апрелендәге «»Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге административ комиссиясен оештыру турында» 11/5 санлы Карарының 3 нче пунктын;

2) Шәһәр Советының 2007 елның 04 апрелендәге «Шәһәр Советының 2006 елның 06 апрелендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге административ комиссиясен оештыру турында» 11/5 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 25/18 санлы Карарының 2 нче пунктын;

3) Шәһәр Советының 2007 елның 25 декабрендәге «Шәһәр Советының 2006 елның 06 апрелендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге административ комиссиясен оештыру турында» 11/5 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 28/14

санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2008 ел, 11 гыйнварындагы 6-8 саннарында бастырылган;

4) Шәһәр Советының 2010 елның 26 маендагы «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге административ комиссиясенең эш Регламентына үзгәрешләр кертү турында» 50/14 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2010 ел, 11 июнендәге 109-111 саннарында бастырылган;

5) Шәһәр Советының 2015 елның 28 декабрендәге «Шәһәр Советының 2006 елның 06 апрелендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге административ комиссиясенең эш Регламентына үзгәрешләр кертү турында» 5/9 санлы Карарын, «Челнинские известия»газетасының 2016 ел, 20 гыйнварындагы 3 санында бастырылган.

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме | Н.Г. Мәһдиев